**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2021 елның 15 июле №48

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Яшел Үзән муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, 2020 елның 4 сентябрендәге 254 номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карары, Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен тапшырырга: тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү, җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча.
2. Әлеге карарны карау өчен Яшел Үзән муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзүче як булырга.
4. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә Татарстан Республикасы «Яшел Үзән» муниципаль районы муниципаль берәмлегенә вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 2014 елның 26 июлендәге 193 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
5. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге

мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**